ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 19.07.2021

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР** № 1626

Яшь гаиләләргә торак сатып алуга бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен 2021 елның өченче кварталына Зеленодольск муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының бер квадрат метры хакының нормативын билгеләү турында

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2021 елның 7 июнендәге 358/пр номерлы «Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының 2021 елның икенче яртыеллыгына бәясе нормативы һәм Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» боерыгы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының бер квадрат метрына торак сатып алуга яшь гаиләләргә бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен 2021 елның өченче кварталына торак мәйданының бер квадрат метры нормативын 58 654 (илле сигез мең алты йөз илле) сум күләмендә билгеләргә.
2. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгына әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:/pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче И.Р. Ганиев